БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 11 2025ел № 315

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары (2020 елның 22 сентябрендәге үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет төзергә.

2. Расларга:

- Балтач муниципаль районының балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет составын 1 нче кушымта нигезендә.

- Балтач муниципаль районының балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка житкерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Житәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «19» 11
315 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет составы

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов Илһам Фидәил улы | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, координацион совет рәисе |
| Заһидуллин Рөстәм Рафис улы | Балтач районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе, координацион совет рәисе |
| Гыйлемҗанов Фирдинант Шәрифҗан улы | Балтач муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча Балтач яшьләр формированиеләре үзәге» директоры, координацион совет секретаре |
| **Совет әгъзалары:**<br>Гайнуллин Дамир Нурмөхәммәт улы | Балтач муниципаль районының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Петров Ильназ Ильич | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Усманов Илдар Котдус улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач муниципаль районы буенча башлыгы, полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| Мөхәрләмов Ренат Камил улы | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе»МКУ башлыгы |
| Гатиятуллина Алсу Фәриз кызы | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20*25* елның «*19*» *11*
*315* номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча координацион Совет (алга таба — координацион Совет) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы учреждениеләре, предприятие, оешма, иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне камилләштерү максатларында төзелгән консультатив-киңәшмә органы булып тора.

2. Совет үз эшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләренә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Советның төп максатлары һәм бурычлары

3. Совет эшчәнлегенең төп максаты булып:

а) патриотик тәрбия системасын үстерү һәм камилләштерү, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә югары патриотик аң, үз Ватанына тугрылык формалаштыру.

4. Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

а) патриотик тәрбия белән шөгыльләнүче яшьләр учреждениеләрен, мәгариф учреждениеләрен үстерү һәм модернизацияләү;

в) балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүнең норматив-хокукый һәм оештыру-методик базасын үстерү;

г) иҗтимагый оешмаларны, мәгариф учреждениеләрен һәм хезмәт коллективларын патриотик тәрбиядә катнашуга җәлеп итү.

## III. Координацион совет составы

5. Координацион совет составы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

6. Координацион совет составына аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашучы рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм башка әгъзалар керә.

Координацион совет рәисе:

а) координацион совет эшенә җитәкчелек итә, координацион совет утырышларында мәсьәләләрне карау исемлеген, вакытларын һәм тәртибен билгели;

б) координацион совет урынбасарлары һәм әгъзалары арасында вәкаләтләрне (бурычларны) бүлә;

в) утырышларны уздыруның коп тәртибен, датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

г) урынбасарларының берсен координацион совет рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгеләп куя;

д) координацион совет утырышларының һәм башка документларының беркетмәләрен раслый.

координацион совет секретаре:

а) координацион совет утырышларында катнаша;

б) координацион совет әгъзаларына утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында утырыш уздыру көненә кимендә өч эш көне кала хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) координацион советның утырышлар беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

Координацион совет әгъзалары:

а) координацион совет утырышларында шәхсән катнашалар;

б) координацион совет компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга чыгаралар;

в) координацион совет карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыралар.

## IV. Координацион совет утырышлары һәм карарлары

7. Координацион совет үз эшен еллык чаралар планы нигезендә төзи. Чаралар планы Координация советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә коллегиаль рәвештә төзелә һәм Координация советы тарафыннан раслана.

8. Координацион совет утырышлары кирәк булган саен көндезге формада яисә читтән торып тавыш бирү рәвешендә, әмма кимендә алты айга бер мәртәбә уздырыла.

9. Координацион совет утырышларын Рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

10. Координацион совет утырышында координацион совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Координацион совет карары аның өчен утырышта катнашучы әгъзаларның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Координацион совет рәисе карары буенча карарлар Координацион совет әгъзаларыннан язмача сорашып белешү (читтән торып тавыш бирү) юлы белән кабул ителергә мөмкин.

11. Координацион совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә Координацион совет секретаре имза сала һәм рәислек итүче тарафыннан раслана. Координацион совет утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр координацион совет утырышын уздырган көннән алып 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм рәислек итүчеләр имзалаганнан соң өч көн эчендә координацион советның барлык әгъзаларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынган органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, шулай ук патриотик тәрбиянең башка субъектларына җибәрелә.

Совет карарлары утырышта катнашучы Совет әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Совет рәисенең тавышы хәлиткеч була.

12. Совет әгъзалары мәсьәләләрне тикшергәндә һәм карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Кабул ителгән карар белән килешмәү очрагында советның һәр әгъзасы беркетмәгә беркетелергә тиешле фикерен язмача бәян итә.

13. Совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Рәис яисә аның урынбасары һәм Секретаре тарафыннан имзалана. Совет карарлары рекомендация характерында.

15. Совет рәисе, ә ул булмаганда рәис урынбасары чираттагы утырышны күчерә яки өстәмә утырышны билгели.

16. Көн тәртибендәге аерым мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен Совет утырышларына чакырылган затларга катнашу рөхсәт ителә.

## V. Советның төп функцияләре

Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

17. Балтач муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча өстенлекле юнәлешләрне, максатларны һәм бурычларны билгели.

18. Балтач муниципаль районында яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшен планлаштыра.

19. Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү буенча теге яисә бу чаралар күрү кирәклеге турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә.

20. Балтач муниципаль районында яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү эшенең торышы турында мәгълүмати-аналитик, белешмә материаллар һәм белешмәләр әзерли.

21. Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча органнар һәм учреждениеләрнең уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм тарата.

22. Яшьләрне патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

23. Совет карарларының үтәлешен тикшереп тора.

## VI. Совет вәкаләтләре

Советның хокуклары:

24. Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшенең торышына комплекслы анализ ясарга.

25. Үз утырышларында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча барлык милек рәвешләрендәге оешмалар һәм учреждениеләр житәкчеләрен тыңларга.

26. Яшьләрне патриотик тәрбияләүнең, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекнең норматив - хокукый һәм оештыру-методик базасын үстерү буенча оешмалар һәм учреждениеләр эшчәнлеген координацияләргә.

27. Җирле үзидарә органнарыннан, вазыйфаи затлардан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан аның эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны соратып алырга.

28. Балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү программалары проектлары буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

29. Балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең сыйфат дәрәҗәсен күтәрү буенча кирәкле оештыру чараларын күрергә.

30. Балтач муниципаль районы башкарма комитеты житәкчесенә Балтач муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча мәгълүмат бирергә.